# Үткәннәр хәтердән җуелмый



Үсеп килүче буынны патриотик тәрбия бирү, илебезнең каһарманлы үткәненә ихтирам тәрбияләү, ветераннарга хөрмәт йөзеннән Борай өченче санлы урта мәктәбендә ветераннар белән очрашу оештырылды.

Тыл ветераны Робис Морзабаев сугышның кырыс еллары, озак көтелгән Җиңү килүен ничек белүе турында исенә төшерде, бу авыр һәм ачы еллар турында сөйләп бирде.

Сугыш чоры баласы Әлфия Фазлытдинова да истәлекләре белән уртаклашты, ә бирегә килүчеләр барысы да авыр, ачлык, сугыш, балачагы турында сөйләгәндә, аны кызгандылар.

Укучылар белән әңгәмәсендә хезмәт ветераны Дәрвис Тажетдинов ата-бабаларыбыз турында хәтерне саклауның мөһимлеге турында сөйләде, яшьләр арасында патриотлык темасына басым ясады. Ата-бабаларыбыз турындагы истәлек безгә кайдан килүебезне, нинди каршылыкларны узуыбызны һәм замана юлында нинди дәресләр өйрәнүебезне аңларга ярдәм итә. Халыклар бердәмлеге, сугыш рухы, чиксез батырлык һәм Ватанга мәхәббәт Бөек Ватан сугышы елларында Җиңүне яуларга ярдәм итте. Бүген безнең барыбыз өчен дә тарихи хәтерне һәм буыннарның дәвамчанлыгын саклап калу, балаларда патриотлык һәм үз иленең киләчәге өчен җаваплылык тәрбияләү бик мөһим. Соңгы еллардагы вакыйгалар шуны күрсәтте.

Безнең ил һәрвакыт дошманга каршы торырга әзер булырга тиеш, ә әзерлекле солдатлардан башка – үз Ватаныбыз патриотларын моны эшләү мөмкин түгел. Ветераннар балаларга яхшы укырга, булачак һөнәрен билгеләргә, намуслы эшләргә теләделәр, малайларга үзләрен һәм якыннарын яклау өчен көчле һәм сәләтле булып үсәргә киңәш бирделәр.

Очрашу ахырында кунаклар шәйморатовчылар белән фотога төштеләр.

**Гөлназ ХУҖИНА.**

# Иҗат күкләрен иңләп...

Дүртенче октябрь көнне Борай район үзәк китапханәсендә "Тамчылар" иҗат оешмасына 50 ел тулу уңаеннан "Иҗат күкләрен иңләп..." дип аталган кичә үтте.

Кичәне "Тамчылар" оешмасы җитәкчесе Фәнзия Мәкъсүтова алып барды. Ул оешманың тарихы һәм әгъзалары белән таныштырып үтте.

Ике сәгатьтән артык дәвам иткән әлеге кичәдә районыбызның каләм осталары, әдәби берләшмәнең элеккеге һәм бүгенге әгъзалары чыгыш ясады.

Каләм остасы, журналист, республика матбугатында башкорт, татар телләрендә йөзгә якын хикәясе, шигырьләре, очерклары белән безгә таныш булган "Алга" гәзитенең ветераны Рәзиф Зиятдиновның гамьле чыгышы уйландырды да, моңландырды да.

«Тамчылар» әдәби берләшмәсе тарихы хакында белешмәләр дә бирделәр.

«Тамчылар» әдәби берләшмәсе оешуга да 50 ел ...Шушы гомер эчендә ниләр булган, оешу чорында кемнәр чишмә башында торган әдәби берләшмә нинди үрләр яулаган? Кыскача гына булса да хатирәләргә бирелеп алыйк әле.

...1974 елның сентябрендә «Алга» гәзите редакциясе каршында "Бөреләр" әдәби түгәрәге оеша. Аның җитәкчесе итеп шигъри җанлы Рәзиф Зиятдинов билгеләнә. Соңрак аны Фәвәзит Әхмәтшин алыштыра. Башта балалар өчен дип ачылган түгәрәккә тора-бара өлкәннәр дә кушыла, каләм тибрәтүчеләр һәм әдәбият сөючеләр саны бермә-бер арта.

Берләшмә әгъзалары шигырь язу белән генә чикләнми, хезмәттәшләре турында мәкалә-очерклар яза, ярыша-ярыша хикәяләр, поэмалар иҗат итә.

Берләшмә әгъзаларының күбесе район төзелешендә, авыл хуҗалыгында эшләүче гап-гади хезмәт кешеләре булган. Матур язучылар Фәйхүнә Әхмәрова, Алия Хәйруллина, Мәгъдән Каюмов, Фәви Гарипов, Әлфидә Галләмова, Фәнилә Гайсина, Наилә Дәүләтгәрәева, Борис Мәгъсүмов, Миләүшә Әхмәтҗанова һәм Әлфия Дәүләтгәрәеваның балалар иҗат төркеме оешмага кушыла. Кыскасы, әдәби берләшмә әгъзалары язылачак әсәрләре, булачак геройлары арасында кайнап йөргәннәр. Любовь Гатауллина, Кәүсәр Әминев, Рәйсә Хәлиуллина, Ләйсән Ахунова, Лүзә һәм Өлфәт Бәдертдиновлар да кызыксыну белдерәләр. Ә Нәфисә Хабибдиярова, Фәнзия Мәкъсүтова, Гөлсимә Зиннәтуллина, Фатыйма Гыйлметдинова, Мәсүфә Әюповалар турында әйткән дә юк... Шуның нәтиҗәсе буларак, «Китап» нәшриятында байтак китаплар дөнья күрә. Аларны район тарихын яктыртучы беренче карлыгачлар дип тә әйтергә була.

Әдәби берләшмә әгъзалары, төп эшләреннән тыш, иҗат белән генә шөгыльләнсәләр дә рәхмәттән башка сүз әйтеп булмас иде. Алар ай саен клубларда әдәби-музыкаль кичәләр үткәргәннәр, мәктәпләрдә укучы балалар белән очрашканнар.

Район халык ансамбльләре белән һәрчак иҗади дуслыкта яшәгәннәр берләшмә әгъзалары. Алар әдәби очрашуларның бизәге булып торган. Әлеге элемтәләр тора-бара иҗади хезмәттәшлеккә әверелгән, күбесенең шигырьләренә көйләр язылган, һәм бу күркәм гадәт бүген дә дәвам итә.

1988 елда "Бөреләр" "Тамчылар"га әйләнә. Хәзер аңа Башкортстан язучылар союзы әгъзасы Фәнзия Мәкъсүтова җитәкчелек итә.

– Бүгенге тантана – минем өчен кадерле көн булып истә калыр. Ул минем яшьлегемне искә төшерә. Нәкъ 25 ел элек оешмага эшкә килдем. Безнең эшебезне аңлаучы да булды, аңламаган кешеләр дә байтак иде, – дип Фәнзия Сәгыйть кызы кадерле сәхифәләрен яңартты. – Ул вакытта әдәбиятка караш башка иде. Оешманың бүгенгесенә күз салам да, теге вакытлар сагындыра. "Тамчылар" оешмасының яшьләр хисабына тулылануын теләр идем. Бу, әлбәттә, җиңел бурычлардан түгел. Ләкин талантлар һәрчак булган, аларны табарга, үстерергә кирәк.

Оешма каршында төбәктәге яшь каләм тибрәтүчеләрне үз тирәсенә туплаган әдәби берләшмәләр уңышлы гына эшләп килә. Тантанада аларны да хөрмәтләделәр. Гомумән, юбилей тантанасында төрле дәрәҗәдәге бүләкләр, котлаулар, рәхмәт сүзләре мулдан булды.

Кичәгә килгән һәрбер кунак "Тамчылар" белән ничек бәйләнештә булганын сөйләп, үз иҗатыннан шигырьләр укыдылар. Ә Флүс Шәрифҗанов гармунда уйнап, моңлы итеп җырлап, кичәгә ямь өстәде.

Шунысы куандыра: районыбызда өлкәнрәк язучы абый-апалары үкчәсенә басып килүче өметле яшьләр, иҗаты игътибарга лаек балалар шактый күп. Бу факт үзе генә дә киләчәгебезнең өметле икәнен күрсәтеп тора.

**Лира ЮРАСОВА.**



**Фотода оешманың беренче һәм әлеге җитәкчеләре Рәзиф Зиятдинов һәм Фәнзия Мәкъсүтова.**